| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.09.2024 Баулы шәһәре № 138

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2021 елның 22 октябрендәге 39 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 Бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына ярашлы, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2021 елның 22 октябрендәге 39 номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының 2021 елның 14 декабрендәге 48 номерлы, 2023 елның 25 маендагы 98 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктны 5 пунктча белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Министрлыгы күрсәтмәсе белән билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 1,2 процент;»;

5 пункчаны 6 пунктча дип санарга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта, үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль район сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров